Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының "Кошки авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
Советы карары белән кабул ителде
2025 елның «08» августы № 131

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Кошки авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы Рәисе
____________________ И.Н.Сираев

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**«Кошки авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр кертү турында**

Кошки ав

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Кошкинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы Кошки авыл җирлеге Советы**

Адрес: 422892, РТ, Алькеевский район с.Кошки, ул. М.Джалиля, 18
факс: 8 (84346) 73-2-50

Адресы: 422892, РТ, Әлки районы, Кошки авылы, М.Джалиля ур, 18
тел: 8 (84346)73-2-50

РЕШЕНИЯ Кошки ав. КАРАР

2025 елның " 08 " августы № 131

Әлки муниципаль районы Кошки авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 76-нчы номерылы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Кошки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Кошки авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 76-нчы карары белән (29.07.2024 елның 102-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Кошки авыл җирлеге территориясендә махсус җиһазландырылган стендларда халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Әлки

районы, Кошки авылы, М. Җәлил ур., 18 йорт (бина җирле үзидарә), Кошки авылы, М. Җәлил ур., 21 йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Кошки авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы Рәисе

И.Н.Сираев

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Кошки авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 131

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Кошки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:
"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".